ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
10.01.2025

**К А Р А Р**
№ 1

## «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдә гражданнарны шәхсән кабул итү үткәрүне тәэмин итү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәүне тәэмин итү, шулай ук гражданнарның җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән мөрәҗәгать итүгә конституцион хокукларын гамәлгә ашыру, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча кабул итү һәм эшне оештыру тәртибен җайга салу максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдә гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдә сишәмбе гражданнарны бердәм кабул итү көне булып тора дип билгеләргә.
3. Җитәкчеләр һәм шуңа вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхсән кабул итү (шул исәптән урынга чыгып кабул итү) уздырырга.
4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдә өстәмә кабул итү көннәре оештыру мөмкинлеген карарга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе Г.Ф. Сабировага йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2025 елның
10 гыйнвары 1нче номерлы карарына
кушымта

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдә гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыру тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдә (алга таба - район Башкарма комитеты) гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карауны оештыру «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - № 59-ФЗ Федераль закон), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - № 152-ФЗ Федераль закон) һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - № 16-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы) нигезендә Электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасын кулланып (алга таба - ЕМСЭД) гамәлгә ашырыла.

2. Район Башкарма комитетында гражданнарны кабул итү Татарстан Республикасының ике дәүләт теленең берсендә (мөрәҗәгать итүче телендә) алып барыла.

3. Район Башкарма комитетында гражданнарны шәхсән кабул итү җитәкчеләр һәм шуңа вәкаләтле затлар тарафыннан эш көннәрендә, атна саен сишәмбе көннәрендә (эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән тыш), махсус җиһазландырылган бүлмәдә, куркынычсызлык чараларын үтәп, район Башкарма комитеты вазыйфаи затларының гражданнарны шәхсән кабул итү графигы (алга таба-шәхсән кабул итү графигы) нигезендә әлеге тәртипкә карата 1 нче кушымтада каралган форма буенча үткәрелә.

4. Район Башкарма комитеты җитәкчесе район Башкарма комитетының вазыйфаи затларын аларның компетенцияләре кысаларында гражданнарны шәхсән кабул итүгә вәкаләтле итәргә хокуклы.

5. Шәхсән кабул итү графиклары (кирәк булганда өстәмә кабул итү көннәрен оештыруны да кертеп), шәхсән кабул итүгә вәкаләтле затларны күрсәтеп, локаль норматив актлар белән раслана һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм район Башкарма комитеты бинасында һәм

структур бүлекчәләрнең һәркем файдалана алырлык урыннарында урнаштырыла.

6. Район Башкарма комитетында гражданнарны кабул итүне оештыру буенча җаваплы затлар булып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге хезмәткәрләре тора (алга таба - гомуми бүлек).

Кабул итүгә язылу, телдән гаризалар, тәкъдимнәр һәм шикаятьләр телефоннан шалтырату барышында кабул итү район Башкарма комитеты секретаре тарафыннан көн саен (эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән тыш) 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр (12.00 дән 13.00 гә кадәр тәнәфес) гамәлгә ашырыла, мөрәҗәгать итүчеләргә кабул итү вакытында аларны кызыксындырган мәсьәләләр буенча аңлатмалар һәм консультацияләр бирелә. Район Башкарма комитеты секретаре тарафыннан кабул ителгән гаризалар, тәкъдимнәр һәм шикаятьләр журналда әлеге тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә языла.

Телдән мөрәҗәгатьләр, шул исәптән телефон аша кергән мөрәҗәгатьләр гражданны шәхсән кабул иткән, ведомствоара электрон документ әйләнеше системасына мөрәҗәгать кергән көнне гомуми бүлек хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә.

7. Гражданнарны район Башкарма комитеты җитәкчесенә, урынбасарларга, район Башкарма комитеты эшләр идарәчесенә шәхсән кабул итүгә алдан язуны район Башкарма комитеты секретаре гамәлгә ашыра. Гражданнарны кабул итүгә вәкаләтле башка җаваплы затлар язылуны гражданның телдән яисә язма рәвештә сорауның асылы бәян ителергә тиешле мөрәҗәгате нигезендә мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыралар.

Язылу, әлеге тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә форма буенча журналда алып барыла. Журналның битләре тегелгән, номерланган булырга тиеш.

8. Башкарма комитетның гомуми бүлеге район Башкарма комитеты җитәкчесенә, урынбасарларга, эшләр идарәчесенә һәм гражданнарны кабул итүгә вәкаләтле Башкарма комитет хезмәткәрләренә шәхси кабул итүгә гражданнардан язма мөрәҗәгатьләр кабул итә. Язма мөрәҗәгатьтә граждан мәсьәләнең асылын күрсәтә, шәхси имзасын куя һәм датаны күрсәтә.

9. Шәхсән кабул итүне оештыру максатларында, гражданнан кергән язма мөрәҗәгать электрон документлар әйләнеше системасында теркәлә.

10. Язма мөрәҗәгать буенча гражданнарны шәхсән кабул итүне әзерләү өчен контроль йөкләмә (резолюция проекты, резолюция) рәсмиләштерелә, язма мөрәҗәгать карала һәм документлар һәм материаллар әзерләнә (кирәк булганда).

11. Язмача яисә телдән мөрәҗәгатьне караганнан һәм шәхси кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затка мәгълүмат биргәннән соң, мөрәҗәгать

итүчегә кабул итү датасы турында язма рәвештә яисә телефон аша билгеләнгән датага кадәр бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

12. Гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыруны һәм уздыруны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар мөрәҗәгать итү мотивларын һәм мәсьәләнең асылын ачыкларга, шулай ук граждан белешмәләренең нигезлелеген һәм дәлилләрен раслый торган документлар белән танышырга хокуклы.

13. Гражданнарны кабул итү һәм аларга хәбәр итү өчен тулы мәгълүматны әзерләү срогы алар тиешле гариза биргән көннән 30 көннән дә артмаска тиеш.

14. Гражданнарны шәхсән кабул итү барышында үз компетенциясенә мөрәҗәгать итүчеләрнең сорауларын хәл итү керә торган вазыйфаи затларның булуы рөхсәт ителә.

15. Куркынычсызлык чараларын арттыру, шулай ук кабул итүче затларның һәм гражданнарның җаваплылыгы дәрәҗәсен арттыру максатларында, кабул итү вакытында гражданнарны шәхсән кабул итү процедурасына фото-, видео- һәм (яисә) аудио- беркетмә ясарга рөхсәт ителә, бу хакта кабул итү башланганчы гражданга хәбәр ителә. Гражданның сурәтен теркәү, аннан соң массакүләм мәгълүмат чараларында, районның рәсми сайтында файдалану һәм халыкка җиткерү процедурасы гражданның язма ризалыгы булганда гына, 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча рөхсәт ителә.

16. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм шундый балаларны озатып йөрүче затлар ия.

Чираттан тыш шәхси кабул итүгә хокукка бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары һәм аларның законлы вәкилләре;

2) «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 13 статьясында күрсәтелгән гражданнар;

3) сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затлар;

4) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре;

5) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

5) кабул итүгә өч яшькә кадәрге балалар белән килгән гражданнар;

6) йөкле хатыннар;

7) махсус хәрби операциядә (СВО) катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары;

8) «Федерация Советы әгъзасының статусы турында һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» 1994 елның 08 маендагы 3-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә үз эшчәнлекләре буенча Федерация Советы әгъзасы, Дәүләт Думасы депутаты дәүләт хакимияте федераль органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чиратта ү кабул ителү хокукыннан файдалана;

9) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда гражданнарның аерым категорияләре беренче чиратта шәхси кабул итүгә хокуктан файдалана.

Беренче чираттагы шәхси кабул итүгә хокукка берьюлы берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән гражданнар шәхсән кабул итү вакытында аларның чираттан тыш яисә беренче чиратта шәхсән кабул итүгә хокукын раслый торган документын күрсәтәләр.

17. Шәхсән кабул ителгәндә, граждан аның шәхесен раслаучы документын күрсәтә.

18. Гражданның телдән мөрәҗәгате эчтәлеге 5 нче кушымта нигезендә гражданның шәхси кабул итү карточкасына кертелә.

Гражданнарның шәхси кабул итү картасына гражданнарны кабул итүче вазыйфаи зат тарафыннан имза салына.

Телдән мөрәҗәгатьтә шәхси кабул итү барышында бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык күренеп торган һәм өстәмә тикшерү таләп итми торган очракта, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгатькә җавап кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат тарафыннан телдән бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү карточкасында язу башкарыла, ул мөрәҗәгать итүченең

шәхси имзасы белән раслана. Гражданның телдән җавапка ризалыгы булмаган яисә мондый ризалык турында шәхси имзасы белән раслаудан баш тарткан очракта, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

19. Кабул итү нәтиҗәләре буенча гражданны шәхсән кабул итү карточкасы ЕМСЭДда шәхси кабул иткән көнне теркәлә.

Шәхси кабул итү барышында килгән язма мөрәҗәгатьләр теркәлергә һәм законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

20. Гариза бирүчегә шәхсән кабул итүгә язылудан яисә шәхсән кабул итүне үткәрүдән баш тартылырга мөмкин, әгәр:

а) мөрәҗәгатьтә аларның чишелеше район Советы, гражданнарны кабул итүче вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булса, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында аңлатма бирелә.

б) мөрәҗәгать итүче куйган сорау буенча аңа элегрәк мотивлаштырылган җаваплар бирелгән, һәм шәхси кабул итү барышында ул телдән мөрәҗәгатьне карау өчен мөһим әһәмияткә ия яңа дәлилләр китермәсә;

в) мөрәҗәгать итүчедә аның шәхесен раслаучы документлар булмаса;

г) мөрәҗәгать итүченең наркотик, токсик яисә алкоголь исереклеге хәлендә булуы яисә агрессиянең ачыктан-ачык билгеләре булган үз-үзен тотышы югары дәрәҗәдә активлык халәтендә булса (күрсәтелгән сәбәп бетерелгәнче).

21. Гражданнарны кабул итүне башка көнгә күчергән яисә кабул итү вакыты үзгәргән очракта, кабул итүгә алдан язылып куелган затларга алдан хәбәр ителә.

22. Район Башкарма комитеты җитәкчесе булмаган очракта (командировка, отпуск, башка хәлләр) кабул итүне район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы яки компетенциясенә әлеге мәсьәләне карау кергән Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары башкара.

23. Район Башкарма комитетының гражданнарны шәхси кабул итүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле затлары кабул итү йомгаклары буенча аналитик белешмә төзиләр, ул түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиешле:

- шәхсән кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны турында;

- уздырылган гражданнарны шәхсән кабул итүләр һәм урынга чыгып шәхсән кабул итүләр саны турында;

- шәхсән кабул итүдә кабул ителгән мөрәҗәгатьләр тематикасы турында;

- шәхсән кабул итү барышында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре.

Аналитик белешмә район Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгына хисап аеннан соң киләә торган айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча (квартал саен), гомумиләштерү өчен җибәрелә.

Район Башкарма комитетының гомуми бүлеге гражданнар мөрәҗәгатьләрендәге белешмәләрне исәпкә алуны һәм анализлауны тәэмин итә һәм мөрәҗәгатьләрнең саны һәм характеры турында район Башкарма комитеты җитәкчесенә даими мәгълүмат бирә (квартал саен).

22. Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча йөкләмәләрне вакытында һәм сыйфатлы үтәүне контрольдә тоту район ЕМСЭД ярдәмендә Башкарма комитетның гомуми бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту үз эченә йөкләмәне контрольгә куюны, йөкләмәне үтәү процессын озата баруны, йөкләмәне контрольдән алуны ала.

23. Гражданнарны шәхсән кабул итүне уздырганда граждан әйләнә-тирәдәгеләрнең тормышы һәм сәламәтлеге өчен турыдан-туры куркыныч тудыручы гамәлләр кылган очракта, кабул итүне алып баручы вазыйфаи зат (яисә вәкаләтле) Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле чаралар күрә. Кирәк булганда эчке эшләр органнары һәм ашыгыч медицина ярдәме хезмәткәрләре чакыртыла. Шәхси кабул итү туктатыла, вазыйфаи зат шәхси кабул итү карточкасына нәрсә турында "Эшкә" дип язып куя.

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ дә гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибенә 5 нче кушымта
Форма
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 10 гыйнвары 1нче номерлы карары белән расланды

**ГРАЖДАННАРНЫ ШӘХСӘН КАБУЛ ИТҮНЕ ИСӘПКӘ АЛУ КАРТОЧКАСЫ**

**№ _____** **Кабул итү датасы:_________**

**Кабул итү уздыру адресы: ___________________________________________**

**Гражданның ФИА:_______________________________________________**

**Туу датасы : _____________________________________________________**

**Телефон элемтә номеры: ________________________________________**

**Яшәү адресы: ____________________________________________________**

**Теркәлү буенча адресы: _____________________________________________**

**Социаль хәле: _________________________________________________**

**Ташламалы состав: ______________________________________________**

**Кабатлылык әйе** ☐ **Соңгы мөрәҗәгать датасы**

**юк** ☐

**Әңгәмә эчтәлеге________________________________________________**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**Кабул итү нәтиҗәсе:**

______________________________________________________________

**Йөкләмә:**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**Телдән җавапка риза** _________________ ________________________
(имза)

**гражданнарны шәхсәр кабул итүне**
**уздырган вазыйфаи затның имзасы ФИА**

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ дә гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибенә 4 нче кушымта
Форма
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 10 гыйнвары 1нче номерлы карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдщ гражданнарны шәхси кабул итү процедурасына фото-, видео- һәм (яисә) аудио- беркетмә ясауга

ризалык

Биектау т.ю.ст.пос. «___» ___________20__ел

Мин, ____________________________________________________________

(Ф.И.А.)

___________________серия _________№ ________________ __________ бирелгән

(шәхесне таныклый торган документ төре)

______________________________________________________________________

(кем тарафыннан һәм кайчан)

_________________________________________

______________________________________________________________________

адресы буенча теркәлгән

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы» МБ МКУ дә гражданнарны шәхси кабул итү процедурасына фото-, видео- һәм (яисә) аудио- беркетмә ясауга ризалыгымны бирәм, минем шәхси мәгълүматларны бирү турында карар кабул итәм һәм гамәлдәге законнар таләпләрен үтәү максатларында аларны тулысынча эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Шул ук вакытта минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык мин тарафтан язма гариза белән кире алынырга мөмкин.

Граждан имзасы _____________ _____________________

(Имза)

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ дә гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибенә 1 нче кушымта
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 10 гыйнвары 1нче номерлы карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ**

**вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү графигы**

| Җитәкченең Ф.И.А. (тулысынча) | Вазыйфасы | Кабул итү адресы | Кабул итү сәгатьләре | Телефон элемтә номеры |
|---|---|---|---|---|
| Хәкимуллин Рамил Фатыйхович | Башкарма комитет җитәкчесе | Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Кооператив ур., 5 й., 2 кат, 204 каб. | Сишәмбе 14.00 дән 16.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-30-61 кабул итү бүлмәсе |
| Вакансия | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (инфраструктур үсеш буенча) | Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Кооператив ур., 5 й., 2 кат, 205 каб. | Сишәмбе 14.00 дән 16.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-30-61 кабул итү бүлмәсе |
| Сабирҗанов Ринат | Башкарма комитет | Татарстан Республикасы, | Сишәмбе | 8 (84365) 2-30-61 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Рәшитович | җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) | Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Кооператив ур., 5 й., 2 кат, 213 каб. | 14.00 дән 16.00 гә кадәр | кабул итү бүлмәсе |
| Булгаков Мурад Рамилевич | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (икътисади мәсьәләләр буенча) | Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Кооператив ур., 5 й., 2 кат, 202 каб. | Сишәмбе 14.00 дән 16.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-30-61 кабул итү бүлмәсе |
| Халитов Илсур Әхмәтсафиевич | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары — мәгариф бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Мәктәп ур., 17 й., 1 кат | Сишәмбе 14.00 дән 16.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-36-01 |
| Сабирова Гүзәл Фәритовна | Башкарма комитет эшләр идарәчесе | Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Кооператив ур., 5 й., 201 каб. | Сишәмбе 14.00 дән 16.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-30-61 кабул итү бүлмәсе |
| Хисамутдинов Рөстәм Шәүкәтович | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Кооператив ур., 5 й., 107 каб. | Сишәмбе, пәнҗешәмбе 13.00 дән 15.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-30-68 |
| Җиһаншина Нурзидә Нәсиховна | ЗАГС бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы, Биектау районы, | Дүшәмбе- Җомга (пәнҗешәмбедән | 8 (84365) 2-36-93 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Биектау т.ю.ст. пос.,<br>Мәктәп ур., 17 й.,<br>2 кат, 117 каб. | тыш) 08.00 дән<br>17.00 гә кадәр,<br>тәнәфес 12.00 дән<br>13.00 гә кадәр | |
| Әскәрова Фәния Камиловна | Архив бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы,<br>Биектау районы,<br>Биектау т.ю.ст. пос.,<br>Профсоюз ур., 1А й.,<br>2 кат | Дүшәмбе -җомга (чәршәмбедән тыш) 08.00 дән<br>17.00 гә кадәр,<br>төшке аш 12.00 дән 13.00 гә кадәр | 8 (84365) 74-7-74 |
| Шумкова Лилия Николаевна | Торакны исәпкә алу һәм бүлү башлыгы | Татарстан Республикасы,<br>Биектау районы,<br>Биектау т.ю.ст. пос.,<br>Кооператив ур., 5 й.,<br>108 каб. | Понедельник, Вторник с 8.00 до 12.00 | 8 (84365) 2-30-82,<br>8 (84365) 2-36-07 |
| Вәлиева Гүзәлия Альбертовна | Опека һәм попечительлек секторы мөдире | Татарстан Республикасы,<br>Биектау районы,<br>Биектау т.ю.ст. пос.,<br>Мәктәп ур., 17 й., 4,5 | Дүшәмбе 08.00 дән 12.00 гә кадәр, сишәмбе 13.00 дән 16.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-32-69 |
| Кошелева Саида Мухамедовна | Балигъ булмаганнар эшләре һәм административ практика секторының баш белгече | Татарстан Республикасы,<br>Биектау районы,<br>Биектау т.ю.ст. пос.,<br>Мәктәп ур., 17 й., 6 каб. | Дүшәмбе, Җомга 08.00 дән 12.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-36-86 |
| Чапурин Станислав | «Татарстан Республикасы Биектау | Татарстан Республикасы,<br>Биектау районы, | Сишәмбе<br>14.00 дән 16.00 гә | 8 (84365) 2-35-88 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Михайлович | муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ башлыгы | Биектау т.ю.ст. пос., Совет ур., 15 й., 2 кат, 209 каб. | кадәр | |
| Камалов Фәрхад Шамилевич | «Биектау муниципаль районы Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы | Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.ю.ст. пос., Пролетар ур., 1 й., | Сишәмбе 14.00 дән 16.00 гә кадәр | 8 (84365) 2-35-19<br>8 (84365) 2-35-97 |

Вәкаләтләренә гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыру кертелгән вазыйфаи зат

Денисова Евгения Михайловна

Элемтә телефоны: 8(84365) 2-30-85

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль
районы Башкарма комитеты» МКУ дә
гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибенә 2
нче кушымта
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2025
елның 10 гыйнвары 1нче номерлы карары белән
расланды

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУдә
гражданнарның телдән мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № т/б | Теркәлүнең кергән номеры | Дата | Гариза бирүченең Ф.И.А. | Гариза бирүченең адресы | Мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге | Карау нәтиҗәсе/ Җавапның чыгу номеры |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль
районы Башкарма комитеты» МКУ дә
гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибенә 3
нче кушымта
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2025
елның 10 гыйнвары 1нче номерлы карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУгә
кабул итүгә язылган гражданнарны теркәү
ЖУРНАЛЫ (алдан язылу буенча)

| № т/б | Дата | Гариза бирүченең Ф.И.А. | Гариза бирүченең теркәлү адресы | телефон элемтә номеры | Мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге | Карау нәтиҗәсе/ җаваплы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |